**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 6 мартындагы 697 номерлы карары**

## 2026 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле милек хакының максималь күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, Татарстан Республикасының 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы законы, әлеге закон кушымтасында бирелгән Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданин милкендә булган һәм салым салынырга тиешле милек хакының максималь күләмен билгеләү методикасы нигезендә, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 40 статьясына таянып, **карар бирәм**:

1. 2026 елга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча гражданнарны торак урыннары алуга мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле милек хакының түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек хакының максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 2 756 628,0 сум;

1.1.2. ике кешелек гаилә өчен – 5 513 256,0 сум;

1.1.3. өч кешелек гаилә өчен – 8 269 884,0 сум;

1.1.4. дүрт кешелек гаилә өчен – 11 026 512,0 сум;

1.1.5. биш кешелек гаилә өчен – 13 783 140,0 сум;

1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 16 539 768,0 сум;

1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен – 19 296 396,0 сум;

1.1.8. сигез кешелек гаилә өчен – 22 053 024,0 сум;

1.1.9. тугыз кешелек гаилә өчен – 24 809 652,0 сум;

1.1.10. ун кешелек гаилә өчен – 27 566 280,0 сум;

1.1.11. унбер кешелек гаилә өчен – 30 322 908,0 сум;

1.1.12. унике кешелек гаилә өчен – 33 079 536,0 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме – 58 218,0 сум.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре башлыклары Р.Х.Шәмсетдиновка, А.И.Салиховка, ВВ.Жаворонковка һәм Р.Р.Фәтхетдиновка, гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондыннан торак урыннарны наем шартнамәләре буенча торак урыннары алуга мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар кеременең һәм милек хакының максималь күләмнәрен кулланырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**